**СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Куркачи, ул. Клубная, 4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб урамы,4

Тел./факс 8(84365) 70-700, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

«26» января 2024г. №92

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»2020 елның 19 маендагы 188 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Ветеринария турында» 14.05.1993 № 4979-1 Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге Советы карар итте

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 маендагы 188 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге Иске Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (27.08.2021 елның 32 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

VIII бүлекнең 183 пунктының икенче абзацында «терлекчелек продуктлары» сүзен «хайваннардан алынган продукция»сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Иске Казан авыл җирлеге башлыгы Г. Р. Закирова